ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.08.2017 пгт. Рыбная Слобода № 179пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләр бирүдән тыш), индивидуаль эшкуарларга субсидияләр бирүне җайга сала торган аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә һәм «2017 елга һәм 2018-2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында» 2016 елның 15 декабрендәге XIV-1 номерлы карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 13 сентябрендәге 162пи номерлы «Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан субсидияләрне стационар ваклап сату предприятиеләре булмаган ерак авыл торак пунктларына илтүче кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә бирү кагыйдәләрен раслау турында» карары;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының «Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү хезмәтләре күрсәтүче юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә - индивидуаль эшкуарларга чыгымнарны каплауга Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 20 августындагы 131пи номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хабибуллин